КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 март г.Казань № 193

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 июль, 516 нчы; 2016 ел, 7 октябрь, 720 нче; 2017 ел, 25 май, 299 нчы; 2020 ел, 18 июль, 605 нче; 2021 ел, 31 май, 424 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1044 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алырга теләүчеләр чит ил юридик затлары, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия

Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлар, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

5.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» 2021 ел, 16 апрель, 252 нче карары белән расланган Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктта:

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) учреждение чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) учреждение экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

9 пунктта:

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«учреждениенең офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган гарантия хатын;»;

түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) учреждениенең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган гарантия хатын.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максатлары;

грант күләме;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар кабул итү сроклары;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

учреждениенең, шулай ук учреждение белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә учреждениенең субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шарты һәм тәртибе;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкин булмавына китерә торган итеп киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү хакында шарт;

учреждение, шулай ук учреждение белән төзелгән шартнамәләр нигезендә

акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела;

грант күчерү буенча план-график.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Учреждение хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча Министрлыкка финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап кертә.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә учреждение тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Министрлык учреждениенең грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Грант бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Учреждение тарафыннан грант биргәндә билгеләнгән шартлар һәм тәртип бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр факты буенча ачыкланган бозулар булганда, шулай ук грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, учреждение Министрлыкның язма таләбен алган көннән 30 календарь көн эчендә алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтара.»;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемено ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, Министрлык учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына алган акчаны кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә яки Министрлыкның язма таләбендә күрсәтелгән учреждение тарафыннан алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтару срогы чыкканнан соң Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны мәҗбүри тәртиптә кире кайтару буенча чара күрә.»;

18 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татар-

стан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният өлкәсендә краудфандинг проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 490 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 807 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәдәният өлкәсендә краудфандинг проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциягә карамаган оешма чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«коммерциягә карамаган оешма экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка

катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.»;

10 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциягә карамаган оешма офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый;»;

23 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чаралар оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 16 декабрь, 1240 нчы; 2022 ел, 15 июль, 678 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чаралар оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның икенче абзацында «30 нчы» сүзен «бишенче» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә

активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

10 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә коммерциягә карамаган оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры (яки) турыдан-туры булмаган (өченче зат аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хатын;»;

19 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы составын, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 25 ноябрь, 1131 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча,

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

1.5 пунктның сигезенче абзацында «максатчан» сүзен төшереп калдырырга;

2.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алучының, шулай ук грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«грант алырга теләүче экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

3.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«грант алырга теләүченең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган гарантия хатын.»;

5.2 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

унынчы абзацта «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алучының, шулай ук грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

6.5 пунктта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә:

8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы боерыгы белән расланган бертип форма буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка башка бюджетара трансферт бирү турында килешү нигезендә бирелә.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1341 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 807 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның икенче абзацында «30 нчы» сүзен «бишенче» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.»;

10 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә коммерциягә карамаган оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры (яки) турыдан-туры булмаган (өченче зат аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хатын;»;

19 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Квалификация күтәрү программаларын узу, тәҗрибә алмашу чараларында катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибен, Мәдәният өлкәсендә проектны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт мәдәният учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибен, Иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 ел, 10 сентябрь, 980 нче карары белән расланган Мәдәният өлкәсендә проектны гамәлгә ашыру өчен

Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт мәдәният учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

5.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы — Р.К.Нигъмәтуллин

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 1 март, 193 нче
карары редакциясендә)

Форма

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең
иҗат коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен
Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алуга
заявка

| | |
|---|---|
| Номинациянең исеме | |
| Проектның исеме | |
| Проектның кыскача эчтәлеге | (проектның төп идеясен чагылдыра торган текст рәвешендә бирелгән проект презентациясе (иң күбе 1000 символ)) |
| Проектның социаль әһәмиятен нигезләү | ______________________________ (проектны булдыруга этәргән хәлне тасвирларга тәкъдим ителә. Карала торган проблема буенча социологик тикшеренү булу. Финанс чараларының булмавы проблема булып тормый. Проблема дигәндә мәдәният, сәнгать өлкәсендә барлыкка килә торган хәл аңлашыла, аны чишү өчен проект тәкъдим ителә дә инде. Проблемаларның тасвирламасыннан проектның максатлары һәм бурычлары барлыкка килергә тиеш (иң күбе 1 000 символ)) |
| Проектның максаты һәм бурычлары | ______________________________ (максат гомуми терминнар белән формалаштырыла, ә бурычлар эшчәнлекнең билгеле бер нәтиҗәләрен характерлый. Сез нәтиҗәдә алырга теләгәнне билгеле торган бурычларны Сез нәрсә эшләргә теләгән бурычлар белән бутарга ярамый) |
| Көтелә торган нәтиҗәләр | |
| Сан ягыннан нәтиҗәләр | ______________________________ (Проектны гамәлгә ашыру чорында ирешү планлаштырылган санлы күрсәткечләр белән |

| | |
|---|---|
| | исәпләнә торган төгәл нәтиҗәләр билгеләнә) |
| Сыйфат ягыннан нәтиҗәләр | ________________________________ (проектны гамәлгә ашыру чорында ирешү планлаштырыла торган, санлы күрсәткечләрдә исәпләнми торган нәтиҗәләр күрсәтелә (социумдагы уңай үзгәрешләр, төгәл социаль проблемаларны хәл итү, максатчан төркемнең тормыш сыйфатын яхшырту һ. б., иң күбе 1 000 символ) |
| Грантның сорала торган суммасы,<br>шул исәптән түбәндәгеләр исәбеннән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты;<br>җирле бюджет;<br>финанслауның башка чыганаклары (кайсы икәнен күрсәтергә) | __________ сум,<br>__________ сум,<br><br>__________ сум |
| Чыгымнар сметасы | Грант алырга теләүченең җитәкчесе, бухгалтеры имзасы һәм грант алырга теләүченең мөһере (булганда) белән расланган аерым биттә (формасы теркәлә) |
| Проектны гамәлгә ашыру срогы | |
| Проектны гамәлгә ашыра башлау датасы | ________________________________<br>(ае, елы) |
| Проектны гамәлгә ашыруны тәмамлау датасы | ________________________________<br>(ае, елы) |
| Партнерларның ниятләрен раслый торган документлар | ________________________________ (проектны гамәлгә ашыруда мәгълүмати, консультация, оештыру, матди һәм (яки) башка төрле ярдәм күрсәтергә әзер булган 10 проект партнерына (оешмаларга һәм (яки) физик затларга) кадәр күрсәтелә. Грант алырга теләүченең теләге белән заявкага (төп партнерларның (югарыда санап үтелгәннәрнең) проектны гамәлгә ашыруда роле һәм конкрет катнашу формалары турында иң күбе биш документ) тегеп куела. |
| Проектларны бергәләп гамәлгә ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү | ________________________________ (оешмалар исемлеге (булганда) күрсәтелә) |
| Грант алырга теләүченең проект буенча күздә тотыла торган эшчәнлек алып бару тәҗрибәсе | Әйе / юк<br>(оешманың эшчәнлек төрен кыскача тасвирларга һәм төп иҗади эшләрен санап чыгарга, шундый |

| | |
|---|---|
| булу | ук проектларны тормышка ашыруда булган нәтиҗәләрне чагылдырырга) |
| Соңгы өч ел эчендә оешмага грант ярдәме күрсәтелдеме? | ___<br>(конкурсларның, иҗади проектларның исемен, грант күләмен, аны алу елын күрсәтергә) |
| Проектта катнашучыларның максатчан аудиториясе һәм географиясе, сан буенча составы | ___<br>___ |
| Проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территория (торак пунктлар, муниципаль берәмлекләр) | ___<br>(торак пунктлар, муниципаль берәмлекләр исемлеге күрсәтелә) |
| Эшчәнлек ысуллары | ___<br>___<br>(түбәндәгеләр турында күрсәтергә тәкъдим ителә:<br>1) эш ничек башкарылачак һәм ни өчен нәкъ менә шундый эшчәнлек ысулы сайлану;<br>2) проектта катнашучыларның – башкаручыларның нәрсә белән шөгыльләнәчәге;<br>3) чаралар ничек узачак (яки эшчәнлек продуктлары ничек сатылачак);<br>4) кайда һәм ничек итеп өстәмә ресурслар җәлеп ителәчәк) |
| Грант алырга теләүченең тулы исеме (теркәлү турында таныклык нигезендә) | ___<br>___ |
| Проектның авторы (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы) | ___<br>___ |
| Грант алырга теләүченең почта адресы | ___ |
| Элемтәгә керү өчен телефон | ___ |
| Электрон почта адресы | ___ |

Заявкага теркәлә торган документлар:

грант алырга теләүченең мөһере (булганда) һәм җитәкченең имзасы белән расланган устав күчермәсе;

грант алырга теләүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

грант алырга теләүченең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият

кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

грант алырга теләүчегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының тиешле проектны муниципаль берәмлек бюджеты акчасы исәбеннән грант күләменең кимендә 100 проценты күләмендә финанслашуга ризалыгы турында гарантия хаты;

грант алырга теләүченең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган гарантия хаты.

Түбәндәгеләрне раслыйм:

грант алырга теләүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмавын;

грант алырга теләүченең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмавын;

грант алырга теләүченең үзгәртеп оештыру (грант алуга дәгъва итүчегә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәскә, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридки зат булган грант алырга теләүченең баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмавын;

грант алырга теләүченең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын;

грант алырга теләүченең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы составын, Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 25 ноябрь, 1131 нче карары белән расланган Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең

иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын;

грант алырга теләүчегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын грант күләменең кимендә 100 проценты күләмендә җәлеп итүне тәэмин итүен.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә грант алырга теләүче турында, бирелә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алу белән бәйле грант алырга теләүче турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирәм.

Грант алырга теләүченең җитәкчесе:

_______________________________________/____________________________/_______________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (вазыйфасы) (имзасы)

20___ ел, «____» ________ М.У. (булганда).

________________________________________